**СОВЕТ ГАБИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422606 с. Габишево,
пр. Молодежный, д.1
тел: 4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГАБИШЕВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-46-57

---

**2023елның «17» октябре** **68 номер**

# КАРАР

**“Габишев авыл җирлеге Советының” Җир салымы турында "2021 елның 19 октябрендәге 84 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору хакында" 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 84 номерлы Габишев авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Габишев авыл җирлеге -**
**Советы рәисе** **Ф.М.Миндубаев**

*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль*
*районының Габишев авыл җирлеге*
*Советының 2023 елның «17» октябрендәге*
*68 номерлы карарына кушымта*

**«Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 84 номерлы Габишев авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

**1) 1 пунктның 1.2 пунктчасы**:

- "һәм объектлар" сүзләрен "һәм (яисә) объектлар" сүзләренә алмаштырырга, "объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләр" сүзләрен "күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлеше" сүзләренә алмаштырырга, "һәм объектларга" сүзләрен "һәм (яисә) объектларга" сүзләренә алмаштырырга.